БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» 04 2021 ел № 161

«Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы, 2021 елның 5 мартындагы 108 номерлы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 декабрендәге 433 номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 19 июлендәге 262 карары белән расланган Чернобыль атом электростанциясендәге һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны исәпкә кую һәм Дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (2 нче кушымта)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктның 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «11) чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;»;

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 3 нче кушымтаның 18 абзацында «гаиләнең балигъ булмаган әгъзаларына - туу турында таныклыклар» сүзтезмәсен «чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе»нә алмаштырырга.

2.2. 3 нче кушымтаның 21 абзацында «язылышу (аерылышу) турында таныклык, бала туу турында таныклык» сүзтезмәсен «чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе»нә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов